СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.02.2022 Баулы шәһәре № 104

Баулы муниципаль районы Советының «Баулы муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы 2018 елның 20 апрелендәге 150 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 7 декабрендәге 1189 номерлы карары нигезендә Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

Баулы муниципаль районы Советының «Баулы муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы 2018 елның 20 апрелендәге 150 номерлы карарына (2018 елның 28 сентябрендәге 177 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 275 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта:

өченче абзацта «компенсация түләүләре,» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «һәм компенсация түләүләрен» сүзләрен төшереп

калдырырга;

5 нче пунктта:

1 нче пунктчада «50» санын «8» санына алмаштырырга;

3 нче пунктчада «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

4 нче пунктчада:

икенче абзацта «25» санын «5» санына алмаштырырга;

өченче абзацта «10» санын «2» санына алмаштырырга;

5 нче пунктчада:

икенче абзацта «35» санын «7» санына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «50» санын «10» санына алмаштырырга;

8 нче пунктта:

беренче абзацта «(компенсация түләүләрен исәпкә алып)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 нче пунктчада «тугыз айлык тариф ставкалары» сүзләрен «бер бөтен сигез айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче пунктчада «өч айлык тариф ставкалары» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

4 нче пунктчада «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы
урынбасары, район Советы
Рәисе урынбасары Р.Г. Хәмидуллин